МИНИСТЕРСТВО
ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
УРМАН ХУҖАЛЫГЫ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

от 23.05.2024 № 190-осн

ш. Казан

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының аерым боерыкларын гамәлдән чыккан дип тану турында

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы норматив хокукый актларын федераль законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының түбәндәге боерыкларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Урманнарны үзләштерү проектына дәүләт экспертизасы уздыру буенча Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы эксперт комиссиясе оештыру турында» 2013 елның 2 августындагы 424-осн номерлы;

«Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының урманнарны үзләштерү проектына дәүләт экспертизасы үткәрү буенча эксперт комиссиясен төзү турында» 2013 елның 2 августындагы 424-осн номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 6 августындагы 310-осн номерлы.

2. Юридик бүлек җитәкчесенә (Т.А.Барсукова) боерык имзаланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек чорда аны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары И.Н.Зариповны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Р.Ә. Кузюров